МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**_29.06.2023__** **№ _237/2-пр_**

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында” 2014 елның 23 апрелендәге 133/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучыга аның үтенече буенча бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

“Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында” Федераль законга үзгәрешләр кертү турында” 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында” 2014 елның 23 апрелендәге 133/2-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны мәгълүматтан файдаланучыга аның үтенече буенча бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә: 2.12 пунктта сигезенче абзацта “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә” сүзләрен “Министрлыкның рәсми сайтында” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Л.Н. Гариповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры – министр М.А. Җәббаров